# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**18.11.2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 18 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча Яңа Саклау авылында теркәлгән һәр балигъ булган һәрбер кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә үзара салым кертергә килешәсезме:

-МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

- Яңа Саклау т. п. Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл төзү;

- Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа Саклау торак пунктында төрле чаралар үткәрү өчен бүләкләр алу;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган _16_ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - _11_ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен _11_катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен _0___ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл жирлегенең Яңа Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау аылы территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча Яңа Саклау авылында теркәлгән һәр балигъ булган һәрбер кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

-МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

- Яңа Саклау т. п. Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл төзү;

- Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа Саклау торак пунктында төрле чаралар үткәрү өчен Бүләкләр, Бүләкләр алу;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Саклаубаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина